| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>**26.04.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 379** |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

"Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" Муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П.Дегтеваның мәгълүматын тыңлаганнан һәм караганнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы "Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар беләнт тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 233нче Карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталындан (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск башлыгы**
**муниципаль районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына кушымта
2019 елның 26 апреле , №379

# Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге тәртип Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлекләр).

2. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә җирлекләр бюджетларына һөнәри керемгә салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар кергән көннән соң квартал саен 3 эш көне эчендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Җирлекләргә бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Җирлек бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчалары хисабына тормышка ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган хокукый акты булу тора.

6. Авыл җирлеге башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

7. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты keременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында кулланылмый торган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет Палатасы карары нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында җирлек бюджеты керменә кире кайтарылырга мөмкин, моңа кадәр алар бирелгән җирлек бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен, әлеге башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган җирлек бюджеты керемена кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемендә алынырга тиеш.

8. Зеленодольск муниципаль районы һәм вазифаи затлар законнар нигезендә тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемендә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

10. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

**Зеленодольск муниципаль**
**Районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**